وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлгездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№15 (112). 25 ноябрь 2011 / 29-зөлхиҗҗә-1432

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ





Кабан арты мәчете имамы РИУ студентларына мәхәллә белән идарә итү серләрен ачты ▷2◁





Насыйх ага нәсихәте ▷3◁





Әни кадере... ▷4◁


## ЯҢАЛЫКЛАР

### РФ ПРЕЗИДЕНТЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ

19 ноябрьдә ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз Россия мөфтиләренең РФ Президенты Дмитрий Медведев белән очрашуында катнашты.

Очрашуның төп максаты - экстремизмга каршы тору - бүгенге көндә бик тә актуаль, чөнки соңгы ике айда гына да Төньяк Кавказда халык арасында соңгы сулышкача экстремистик идеологияне таратуга каршы торган абруйлы дин әһелләре үлде. Дини экстремизмның сәбәбе, Президент фикеренчә, яшьләрнең элементар дин нигезләрен белмәүдән килә. Шуңа да алар төрле радикаль эктремистик юнәлешләргә бирешүчән була. "Ил җитәкчелеге бик яхшы аңлый: бары тик дин әһелләре генә, традицион ислам каннуннарын таратучылар гына радикализмга һәм экстремизмга каршы тора алалар", - дип белдерде Илбашы.

### I ӨЛКӘАРА МӨСЕЛМАН ЯШЬЛӘРЕ ФОРУМЫ ҮТТЕ

19 ноябрь көнне Ульяновск шәһәрендә "Ислам яшьләре Россия киләчәге өчен" дип аталган I өлкәара мөселман яшьләре форумы үтте. Форумда ТР мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре - яшьләр белән эшләү бүлеге җитәкчесе Айнур Солтанов, уку-укыту бүлеге белгече Айдар Кәрибуллин катнашты. "Массакүләм мәгълүмат чаралары аша җәмгыятькә үтеп кергән ялгыш стереотиплар", "Ислам динендә мәзһәбләр", "Яшьләрдә мөселман әхлагын тәрбияләү" дигән темаларга докладлар тыңланылды. А.Солтанов: "Мондый форумнар үтүе бик тә мөһим. Ил сәясәтенә диннең кайта баруы авыр процесс. Монда җәмгыятьнең барлык катламнары - ил, дини һәм иҗтимагый оешма җитәкчеләре, галимнәр һәм яшьләр катнашырга тиеш. Яшьләргә ватанпәрвәрлек тәрбиясе бирү дә мөһим һәм Ульяновскта мондый форумның үтүе илнең ислам җәмгыяте каршында торган максатларына ирешүдә зур адым булды", - дип билгеләп үтте.

### ПЕРМЬ КАЛЛИГРАФЫ ЯШЬЛӘР БЕЛӘН ОЧРАШТЫ

21 ноябрь көнне "Алтын урта" яшьләре Пермьнән килгән каллиграф - Эдуард Димасов белән очрашты. Эдуард - яшь булуына да карамастан, танылырга өлгергән каллиграф. Аңа чит илләрдәге төрле оешмалар заказ белән мөрәҗәгать итә. Эдуард Димасов узган якшәмбедә узган "Ислам граффити фестивале"ндә дә катнашкан иде.

Яшьләр каллиграфның эшләре белән танышты, аңа күптөрле сораулар бирде, үз фикерләре белән уртаклашты. Эдуард үзенең классик стильдә түгел, ә заманча, модерн стилендә эшләве турында әйтте. Чит илләрдә каллиграфик эшләнмәләрнең кыйммәт йөрүен, әмма Россиядә бу хезмәтнең түбән бәяләнүен билгеләп үтте ул.

Очрашудан соң истәлекләр дәфтәренә "Алтын урта" дип, үз стилендә язып та калдырды Эдуард. Ул Казанда мөселман яшьләре өчен мондый җыелу мөмкинлеге һәм күптөрле чаралар уздырылуына сөенүен дә яшермәде.

# ХӘЕРЛЕ ЕЛЛАР БУЛСЫН!

**Бүген ай календаре буенча мөселманнарның Яңа елы - Мөхәррәм ае башлана. Һиҗри ел исәбе буенча 1432 ел белән дә саубуллашабыз. Мөселман календарендa еллар исәбе безнең эраның 622 елының 16 июленнән башлана.**

**Бу көнне пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) якын дусты, сердәше һәм фикердәше, беренче сәхабә хәзрәти Әбү Бәкер Ситдыйк белән эзәрлекләүдән качып, туган шәһәре Мәккәдән Мәдинәгә күчәргә мәҗбүр була. Соңыннан башка мөселманнар да күченә. Күченүне гарәпләр "һиҗрәт" дип атый. Шуңа күрә мөселман елы да әлеге исем белән йөртелә. Һиҗрәт исламны ныгытуда һәм җәелдерүдә әһәмиятле роль уйный: бер кабилә эчендә генә бикләнеп калмау, мөселман мәхәлләсенең дәүләткә әйләнүенә, дини тәгълимат эшләүгә мөмкинлек бирә.**

**Мөселманнар елны Ай йөреше белән хисаплый: Кояш баеганнан соң, күктә ай бик нәзек, урак кеби күренгән вакытта ай башланыр. Ай елын, гадәттәгечә, 12 ай тәшкил итә. Ул, гадәттә, 354 көннән тора. Һәр өченче ел - кәбисә ел, ул 355 көннән килә.**

**Мөхәррәм - гарәпчә "изге, васыятьле", дигән мәгънәне аңлата. Бу ай - исламдагы дүрт изге айның берсе. Исламда Мөхәррәм мул итеп сәдака өләшү, шәфкатьлелек белән шөгыльләнү, игелек күрсәтү ае булып тора.**

**Мөхәррәмнең беренче ун көне мәрхәмәтле санала. Мәсәлән, Мисырда бу вакытта никахка керәләр. Мөхәррәмнең 9-10 нчы көннәрендә Гашура бәйрәме билгеләп үтелә. Сөнниләр бу көнне Аллаһ тарафыннан ун пәйгамбәргә җибәрелгән ун изгелекне, шигыйләр исә имам Хөсәеннең үлемен искә ала. Мөхәррәмнең 16 нчы көне Кыйбла урнашу көне буларак билгеле.**

**Пәйгамбәребез Мөхәммәт (с.г.в.): "Рамазаннан соң ураза өчен Аллаһның иң хәерле ае - мөхәррәм ае, ә фарыздан соң иң хәерле намаз - тәһәҗҗүд намазы", - дигән.**

**Үзәкләшкән дини оешма –**
**ТР мөселманнары**
**Диния нәзарәте рәисе,**
**мөфти**
**Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

## Мөхәррәм ае мөбарәк булсын!



***Бүген, ягъни 25 ноябрь көнне, кояш офык артына күмелү белән үк, һиҗри ел исәбе буенча 1433 нче ел башланачак. Без сезне газетабызның алдагы саннарында ислам динендә ел башы булган Мөхәррәм ае, аның тарихы, фазыйләтләре, бу айда үтәргә мөмкин булган нәфел гыйбадәтләре хакында таныштырып үтәрбез.***

Әлхәмдүлилләһи Раббиль галәмин. Вәссәлатү вәссәләмү галә әшрәфил әнбиәи вәл мүрсәлин. Вәгалә әлиһи вәсахбихи әҗмәгыйнь.

Аллаһ Раббуль Гыйззә үзенең сөйгән колларына зур мөмкинлекләр бирә. Адәм баласы Аның чиксез рәхмәтенә ирешү өчен төрле гыйбадәтләр кылып, Тәрбиячесенә якыная ала. Динебездә иң олы гыйбадәтләрнең берсе - ураза. Мөэмин-мөселманнар Рамазан-шәриф аенда уразалар тотып, Раббыбызның рәхмәтенә ирешергә ашыга. Ләкин, Рамазан ае узды да, шуның белән ураза бетте, дигән сүз юк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) безгә башка айларда да уразалар тотып, Аллаһның рәхмәтенә ирешергә нәсихәт кыла. Ул да булса, һәр айның башы, уртасы һәм ахырында өчешәр көн ураза тоту. Шулай ук һәр атнаның дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе (кече атна) көннәрендә дә теләгән кадәр ураза тотарга мөмкин. Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Дөреслектә, дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәре - җәннәт ишекләре ачыла һәм җәһәннәм ишекләре ябыла торган көннәрдер. Шушы көндә адәм балаларының кылган гамәлләре Аллаһы Тәгалә хозурына аша. Ә мин үз гамәлләремнең Раббым Аллаһ хозурына уразалы килеш ирешүен телим", - дип әйткән.

Мөхәррәм ае - изге ай. Беренчедән, ислам җәдвәле буенча һиҗри ел исәбе - яңа ел шушы Мөхәррәм аеннан башлана. Икенчедән, пәйгамбәребез (с.г.в.) шушы Мөхәррәм ае турында болай дигән: "Рамазан-шәриф аеның уразасыннан соң, иң хәерле уразагыз Мөхәррәм аенда тоткан уразагыз булыр". Шушы айда бер мөселман ихлас күңеле белән бер генә көн булса да ураза тотса, Аллаһ Хаккуль Гыйззә бу бәндәгә чиксез әҗер-саваплар насыйп итәр.

**(Мөхәррәм аендагы Гашура көне турында вәгазь газетабызның киләсе санында тәкъдим ителер.)**

**Илфар хәзрәт ХӘСӘНОВ,**
**Казандагы "Мәрҗани" мәчете**
**имам-хатыйбы**

*Әлфәс хәзрәт ГАЙФУЛЛИН:*

# "МӨСЕЛМАННАРНЫҢ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ ИҢ ЗУР КИМЧЕЛЕК – МӘГЪЛҮМАТ ҖИТМӘҮДӘ. ЧАЛЛЫДА БУ МӘСЬӘЛӘГӘ ЗУР ИГЪТИБАР БИРЕЛӘ"



***– Әссәламегаләйкүм, Әлфәс хәзрәт! Һиҗри ел исәбе буенча 1432 нче ел да төгәлләнеп килә. Ислам дөньясы быел вакыйгаларга бик тә бай булды. Үтеп баручы ел Сез җитәкчелек иткән Чаллы мөхтәсибәтенә нинди куанычлы вакыйгалар, истә калырлык яңалыклар алып килде?***

– Иң беренче чиратта, мөселманча Яңа ел белән барлык дин кардәшләребезне дә тәбрик итәсем килә. Ул барчаларыбызга да иминлек, бәрәкәт алып килсә иде. Әлхәмдүлилләһ, 1432 нче һиҗри ел, чыннан да, ислам дөньясында, республикабыз тормышында вакыйгаларга бик тә бай булды. Безнең өчен шуның иң әһәмиятлесе – ТР мөселманнарының чираттан тыш узган V корылтае. 13 апрельдә булган съезд күп кенә үзгәрешләр алып килде. Ул безнең мөхтәсибәтебезне дә читләтеп узмады. Мең елдан артык бабаларыбыз алып барган хәнәфи мәзһәбеннән чыкмыйча, шушы юнәлешне генә алып бару өчен зур мөмкинлекләр туды. Әлхәмдүлилләһ, бүгенге көндә ата-бабаларыбыздан килгән әдәп-әхлак рәвешендә эшләребезне алып барабыз.

Чаллы мөхтәсибәтенә ныклап тукталсак, быел берничә ел хыялланып килгән эшләребез тормышка ашты. Иң беренче чиратта, бу – мөселман балалары өчен интернат ачылу. Балаларыбыз дөньяви мәгариф учреждениесендә белем алып, аннан соң интернатка кайтып, анда дини гыйлем дә үзләштерә алачак. Без балаларыбызны милли әдәп-әхлак кануннары белән тәрбия кыла алачакбыз. Үзебезгә киләчәкне шул рәвешле әзерләргә ниятлибез. Алар, алдагы тормышларында имамнар гына түгел, ә бәлки, чын мәгънәсендә, иманлы-ихласлы шәхес булыр. Бу – безнең күптән көтелгән хыялыбыз иде. Икенче зур вакыйга – Корбан бәйрәмендә мал чалу-сую гамәлен мәчетләрдән читтә башкаруны оештыра алдык. Монысы да күптәнге хыялыбыз иде. Мәчетләр тирәсендә корбан чалу матур күренеш түгел. Ун-унбиш кенә сарык суйганда бу хәлне кабул итә ала идек әле, тик йөзләгән хайван сую өчен заказлар кабул ителә башлагач, ул матур күренешкә әйләнмәде. Чөнки мондый көнне мәчет әйләнәсендә бәйрәм булырга тиеш: халыкка намазлар укырга өйрәтеп, вәгазьләр сөйләсәк, тирә-юнебезгә мөмкин кадәр күбрәк бәйрәм төсмере бирсәк, иң хәерлесе шул булыр, дидек. Мәчетләр тирәсендә быел хайванның канын, эчке әгъзаларын көндез чыра яндырып эзләсәң дә, таба алмый идең. Шәһәребездә мөселман булмаганнар да яши. Мәчетләр тирәсендә, йорт яннарында корбан чалулардан канәгать булучыларга караганда риза булмаучылары күбрәк иде. Исламның хак, пакь дин икәнен раслау өчен кулыбыздан килгәннең барысын да эшләдек. Шәһәр администрациясе белән сөйләшеп, корбан чалу урыны әзерләп, сату-алу эшләрен дә шунда оештыра алдык. Бу эш безнең тарафтан бик яхшы үтте, бар шәһәр кешесе дә канәгать калды. Бездәге кебек итеп республикабызның башка шәһәрләре дә эшне оештыра алса, җәмгыятебездә мөселманнарга караш бөтенләй башка булыр иде. Бу мактануым түгел. Без һәрбер үткән елга шөкер итәбез. Һаман да алга омтылабыз, мәчетләребезгә килүче яшьләр саны артканнан арта бара.


*(Ахыры 2 нче биттә.)*

## Кабан арты мәчете имамы РИУ студентларына мәхәллә белән идарә итү серләрен ачты

***"Икътисад" белгечлеге буенча белем алучы Россия ислам университеты студентлары чираттагы идарә итү мастер-классында катнашты. Мастер-классны Кабан арты мәчете имамы Сәетҗәгъфәр хәзрәт Лотфуллин үткәрде, дип хәбәр итә islam-portal.ru сайты.***



Әлеге мастер-класс мәчет имамнарының вәгазь сөйләү, иганәчелек һәм социаль эшчәнлекне бергә алып барып, күләмле идарә итү хезмәте башкаруларын күрсәтүгә юнәлтелде. Күп очракта без имамнарны өммәтебез әйдәманы буларак түгел, ә бәлки, дин әһеле буларак кына кабул итәбез. Ә бит ул, иң беренче чиратта, яхшы житәкче булырга тиеш.

Мастер-класс башында ук Сәетҗәгъфәр хәзрәт Ислам динен кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге мәчет тарихына тукталды: ул 1926 елда төзелә һәм озак та үтми ябыла. 1990 елда гына ул Казан шәһәре мөселманнары ярдәме белән Исхак хәзрәт Лотфуллин җитәкчелегендә үз ишекләрен кабат ача. Бүгенге көндә мәчеттә зур иҗтимагый эш алып барыла, анда Казан имамнары киңәшмәсе, мөселман хатын-кызлары клубы, милләтара мәдәният һәм мәгърифәт үзәге, рухи сәламәтләндерү бүлекләре эшләп килә.

Милләтара мәдәният һәм мәгърифәт үзәге 2008 елдан башкалабыздагы өч балалар йортын шефлыкка алды. Рамазан аенда һәм дини бәйрәмнәрдә Казанның Киров, Идел буе районнары һәм Дәрвишләр бистәсендәге балалар йортларында тәрбияләнүче ятимнәр өчен мәҗлесләр уздырыла, аларга кием-салым һәм бүләкләр таратыла. Бу эш ятим балаларга булышу йөзеннән генә түгел, ә бәлки, хәзерге мөселманнарда яклаусыз калган балаларга карата җаваплылык хисе тәрбияләү максатыннан үткәрелә. Чөнки безнең көннәрдә ятим балалар саны, статистик мәгълүматларга караганда, Бөек Ватан сугышыннан соңгы еллар белән чагыштырганда да күбәеп китте. Ташлап калдырылган балаларның күпчелегенең әти-әнисе исән. Алар физик яктан "исән" булсалар да, рухи яктан үле: алар - наркотиклар һәм исерткеч эчемлекләр кулланып, бу дөньяның алдавыч рәхәтлегенә бирелгән һәм Кыямәт көне булачагын оныткан кешеләр.

Очрашуда Сәетҗәгъфәр хәзрәт мәхәллә кешеләре реабилитация үткән рухи сәламәтләндерү бүлеге эшчәнлеге турында да сөйләп үтте.

Әйтеп үтелгән юнәлешләрдән башка, мәчеттә нәшрият эшчәнлеге һәм, бина иске булу сәбәпле, даими рәвештә төзәтү-төзекләндерү эшләре алып барыла, яшь буынны тәрбияләү юнәлешендә спорт программалары тормышка ашырыла.

Әлеге һәм башка эшләр белән дә җитәкчелек итәргә кирәк, шуңа да хәзерге заман мөселманнарына оешма икътисады, бухгалтериядәге исәп-хисап, идарә итү нигезләре турында белемнәр үзләштерү бик тә мөһим.

Нәкъ менә шушы юнәлеш буенча Россия ислам университындагы теология факультетының "Икътисад" белгечлегендә укучыларга белем бирелә дә инде.

***Галим ВАХИТОВ,***
***РИУның ислам икътисады һәм идарә итү кафедрасы мөдире; Рәзинә ГАЙСИНА,***
***РИУ студенткасы***

## Мәрхәмәтле булыйк!




Эльза Кадыйрова - безнең ярдәмгә мохтаҗ мөселман кардәшебез. Кечкенәдән ул әти-әнисен күрми үсә, кызчыкны дәү әнисе тәрбияли. Күптән түгел Эльза әнисен үле килеш таба, аны соңгы юлга озата. Хатын-кызның бәхете ирдән диләр. Кызганыч, беренче иреннән ике бала табып, Эльза аерылырга мәҗбүр була. Хәзерге көндә аның балалары Эльзаның торыр урыны булмаганга күрә, иренең туганнарында торырга мәҗбүр. Ана кызчыкларын бик сирәк күрә. Янәдән тормышын җайга салырга ниятләп, Эльза икенче тапкыр кияүгә чыга. Ләкин ире Эльзаның авырлы икәнен белгәч, аны ташлап китә. Өч айдан дөньяга нәни сабый туачак. Яшь ананың эшләргә мөмкинчелеге юк, булышыр кешесе дә юк - ул берүзе. Хәзерге көндә танышбелешләре бераз ярдәм итә, ләкин һәрберсенең үз тормышы, бала туганнан соң, Эльза үзен һәм баланы аякка бастырырга мәҗбүр. Әйдәгез, мәрхәмәтлелек күрсәтик! Эльзага кулыбыздан килгән кадәр ярдәм итик!

Эльза Кадыйровага ярдәм итәргә теләүчеләр "Зәкят" хәйрия фондына мөрәҗәгать итә ала:

***Адрес: 420111 Татарстан, г. Казань, ул.Лобачевского, д. 6.***
***Тел: +7 (843) 236-4-632; 264-60-08; факс: 236-37-62.***
***Сайт: www.закят.рф.***
***e-mail: fondzakyat@yandex.ru.***
***Шулай ук акчаларны түбәндә китерелгән исәп-хисапка да күчерергә мөмкин:***

***ИНН 1655068682***
***ОГРН 1091600003153***
***р/с 40703810400020000071 в ОАО "Ак Барс" Банк в г. Казани***
***к/с 30101810000000000805***
***БИК 049205805***
***Назначение платежа: благотворительная помощь Кадыровой Э.В.***

*Әлфәс хәзрәт ГАЙФУЛЛИН:*

# "МӨСЕЛМАННАРНЫҢ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ ИҢ ЗУР КИМЧЕЛЕК – МӘГЪЛҮМАТ ҖИТМӘҮДӘ. ЧАЛЛЫДА БУ МӘСЬӘЛӘГӘ ЗУР ИГЪТИБАР БИРЕЛӘ"

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

***– ТР мөселманнары Диния нәзарәте мөселман яшьләре белән эшләүгә аеруча зур игътибар бирә башлады. Халык телендә Чаллы шәһәрен "яшьлек шәһәре" дип тә йөртәләр. Чаллы мөхтәсибәте яшьләр белән ни рәвешле эш алып бара? Нинди проект-чаралар үткәрү өстендә эшләдегез? Нинди кыенлыклар белән очрашырга туры килде? Яшьләрне начар гадәтләрдән саклап калу, аларның ялын файдалы оештыру буенча ниләр эшләнде? Тагын ниләр планлаштырасыз?***

– Кыенлыклар бар, без авырлыклардан зарланмыйбыз. Һәрвакытта да эшләргә, хәрәкәт итәргә кирәк. Безнең Чаллы шәһәрендә яшьләр белән эшләү идарәсе инде дүрт-биш ел эшләп килә. Аның җитәкчесе – Гаптрәшит хәзрәт Кормалиев. Оешмадагы һәрбер тармак буенча җаваплы кешеләр билгеләнгән: тел-сәнгать, дәгъват, спорт, викторина-конкурслар оештыру буенча һ.б. Бу – безнең мөхтәсибәтнең яшьләр белән эшләү идарәсе, ул иҗтимагый оешма. Аның әгъзалары шәһәрдә үтә торган барлык чараларда да катнашырга тырыша, алар бер команда булып эшли. Ярышларда еш кына призлы урыннарга лаек булалар. Аларның команда булып туплануы – Чаллы мөхтәсибәтендә яшьләр белән эш барганлыгын күрсәтә. Без бу идарәдән бик тә канәгать. Алар мәктәпләр, колледжлар, югары уку йортлары белән дә эш алып бара. Студентлар белән аралашалар, кунакка йөрешәләр. Яшьләр идарәсенең мөхтәсибәтебездә үз бүлмәсе бар. Алар шунда "түгәрәк өстәл"ләр оештыра, уртак утырышлар үткәрә. Бу идарә эшчәнлегендә тагын бер зур юнәлеш – ул спорт. Моның белән генә чикләнмичә, ислам дине кануннары буенча яшәргә читенсенеп йөргән яшьләрне дә хак юлга алып кереп китә алар. Безне иң нык шатландырганы шул. Спортны гына алсак та, алар үз ишләре арасында шул спорт белән генә булса да, дәгъват алып бара алалар. Яшьләребез динебезнең яшәү рәвеше икәнлеген ачып бирә. ТР мөселманнары Диния нәзарәте оештырган Изге Болгар җыены, мөселман яшьләре фестивале кебек чараларда да яшьләребез актив катнаша. Мөхтәсибәтебездә яшьләр активына килгәндә, алар чама белән егермеләп кешегә җыела. Яшьләр программасы нигезендә Диния нәзарәте кубогына республикакүләм спорт ярышлары да үткәреп киләбез.

***– 25-28 ноябрь көннәрендә Чаллыда узачак "Милләтем киләчәге" дип исемләнгән Татар яшьләре төбәкара проектында мөселман яшьләре катнашачакмы?***

– Бу чарада катнашу өчен кешеләр билгеләнде, анда яшь имамнарыбыз катнашачак. Яшьләр идарәсе тулаем шушы чара эчендә кайнаячак. Билгеләнгән кешеләребез кайда-ничек нинди мәсьәләләрне күтәрергә, ни рәвешле дәгъват эше алып барырга тиеш икәнлеге ачыкланды. Мөхтәсибәтебездәге яшьләр оешмасының мондый чараларда катнашуы безне куандыра. Әлеге чарада да бергәләшеп милли мәсьәләләрне күтәрә алырбыз, дип уйлыйм.

***– Сезнең мөхтәсибәт массакүләм мәгълүмат чаралары, радио-телевидение белән дә актив эшли. Үзегезнең сайтыгыз бар. "Чаллы-ТВ"да атна саен "Кыйбла" исемле тапшыру алып барасыз. Боларның һәммәсе дә нәтиҗәле эшләү өчен уңай шартлар тудыра. Бу юнәлештә эшне оештыру авыр булдымы? Башка мөхтәсибәтләргә дә эшне кайдан-ничек башларга киңәш итәр идегез?***

– Мөселманнарның эшчәнлегендә иң зур кимчелек – мәгълүмат җитмәүдә. Безнең мөхтәсибәттә бу мәсьәләгә зур игътибар бирелә. Бу – мөхтәсибәтнең, мәчетләрнең эшчәнлеген билгеләүче төп юнәлешләрнең берсе. Шәһәребездәге радио-телевидение, барлык татар һәм рус телләрендә нәшер ителүче газета-журналлар белән эшләргә тырышабыз. Үзебезнең вәгазьләребезне, язмаларыбызны бирәбез. Шәһәребездәге "Күңел" радиосы белән берничә ел дәвамында актив эшләп киләбез. Без аларга бик тә рәхмәтле. Чаллы телевидениесендәге "Кыйбла" тапшыруы эшли башлаганга инде унбишләп ел булды. Соңгы вакытта аның сыйфаты тагын да яхшырды, мәгълүмати яктан баеды: мөхтәсибәт яңалыкларын гына түгел, республикабыз хәбәрләрен дә яктыртабыз. Хәзерге вакытта тапшыруны мин үзем алып барам. Атна саен эфирга чыгучы "Кыйбла" тапшыруын "Чаллы-ТВ"да үзеңә уңай вакытта карарга мөмкин: пәнҗешәмбе (кич белән), җомга (15.30), шимбә (иртән). Карарга, белергә теләгән кешегә кешегә бар мөмкинчелек тудырылган. Тапшыруны кич беләнгә генә куйсак, аны бөтен кеше дә карый алмый бит. Төрле вакытка куелгач, халык та бик канәгать. Чаллы мөхтәсибәтендә үткән бөтен чаралар шул тапшыруыбызда яктыртыла. Шулай ук оператив яңалыкларыбызны "Хәбәр"ләр тапшыруына биреп барабыз. "Күңел" радиосы белән исә Рамазан аенда эшчәнлегебезне тагын да арттыра төшәбез. Вәгазьләр сөйлибез, биш вакыт намаз, авыз ачу вакытлары сәгате-минуты белән радиодан әйтелеп барыла. Көн дәвамында радио аша ураза тотучыларга мәгълүмат ирешелә. Элек һәр җомга көннәрендә радиодан вәгазьләр бары тик иртәнге сәгать тугызда гына тапшырылган булса, быелдан башлап шул вәгазь хәзер көненә өч-дүрт тапкыр яңгырый башлады. Әйтергә кирәк, бу юнәлештәге эшчәнлегебез тулы көченә бара. Дәгъват-нәсихәтләребез белән шулай ук "Ислам нуры", "Яшьләр" кебек газеталар аша да танышып барырга мөмкин. Соңгы вакытта балалар өчен дә дини газета бастыра башладык. Брошюралар да чыгарабыз. Сайтыбыз да (islamtatar.ru) гел яңарып тора, анда дин яңалыклары, вәгазьләр, аудио– һәм видеоматериаллар шактый күп.


***– Сез администрация белән ныклы элемтәдә торасыз. Бу Сезнең мөхтәсибәт эшчәнлегендә дә яхшы чагыла (ифтарлар оештыру, пансионат ачылу, корбан чалу йоласын башкару һ.б.). Кич белән мәчетләр каршында дини дәресләр үткәрү, балалар өчен лагерьлар оештыру юнәлешендә нинди тәкъдимнәрегез бар?***

– Балалар өчен лагерьлар оештыруга зур игътибар бирәбез. Балалар – ул безнең киләчәк. Монда яхшы нигезне сала барырга кирәк. Акча-финанс мәсьәләләре белән кыенлыклар туган очракта да, лагерьларны төрлечә оештырырга мөмкин: куна торган итеп яисә иртән килеп, кич кайтып китә торган итеп. Матди мөмкинлекләребез начар, шуңа лагерьлар оештырмыйбыз, дип акланырга кирәк түгел. Без лагерьларны кызлар өчен аерым оештырабыз. Беренче елны дин нигезләрен өйрәтсәк, икенче елга исламча яшәү рәвешенә төшендерәбез, өченче елны аларга экскурсия-походлар оештырабыз (кайчакта ул өч-биш көнлек була). Төрле җирләргә сәяхәт итәбез. Бу рәвешле алар, беренчедән, үзләре ныгыса, икенчедән, башкаларга да яхшы дәгъват була ул. Ягъни исламча яшәү рәвешенә ныклап өйрәнәләр. Үзләренә ашарга пешереп, бер-берсенә дәресләр үткәреп, үз урыннарын җыеп, ял вакытларын файдалы үткәрә. Безнең берничә төркем шундый лагерьларда тәрбияләнде инде. Алар хәзер җитәкчеләр, укытучылар булып хезмәт итә. Бу – бик тә яхшы күренеш. Бездә шулай ук "Кол Шәриф оныклары" проекты эшләп килә. Биш-алты ел инде мәктәп яшендәге балаларга төрле конкурслар үткәрәбез. Соңыннан, иң лаеклы оныкларны билгелибез. Алар елдан-ел арта бара. Бу – балаларны дөрес юнәлешкә кертү, аларны динебез белән таныштыру, аларга шәригать кушканча яшәү рәвешен өйрәтү өчен яхшы форсат. Яшьләребезгә киләчәк алмаш тәрбияләү бездә шул рәвешле бара. "Кол Шәриф оныклары" проектында үскән балаларның берсенең дә чит-ят, начар юлларга кереп киткәне юк. Алар бит 200-300 бала арасыннан сайлап алына. Шул балаларның берсе дә мәчет тирәсеннән әллә кая еракка китми, Аллаһка шөкер...

***– Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт. Киләчәктә дә зур уңышлар насыйп булсын Сезгә!***

**Әңгәмәдәш –**
**Нияз САБИРҖАНОВ.**

# ГАБДЕННАСЫЙР ХӘЗРӘТ



***Әминов Габденнасыйр (ахун, дәмулла Габденнасыйр бине Мөхәммәдәмин әл-Буави) (1806–1886) – танылган дин һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог. Ул 1806 елны дин әһелләре гаиләсендә дөньяга килә. Иң әүвәл Якуб бине Яхъя әл-Бәрәскәви мәдрәсәсендә укый. Аннан соң, озак еллар дәвамында Бохарада Габделмөэмин бине Үзбәк әл-Бохари, Ходайбирде әл-Байсуни, Салих бине Надир әл-Хөҗәнди һәм башка галимнәрдән тирән дини белем ала.***

1852 еллар тирәсендә Буа шәһәренә имам-хатыйб, мөдәррис итеп билгеләнә. Биредә ул халыкны уку-укыту, вәгазьләү, аларны әхлакый яктан тәрбияләү өчен зур көчен куя. Аның тырышлыгы белән Буа мәдрәсәсе даны тирә-якларга тарала. Ул Сембер губерниясенең иң зур уку йортларының берсенә әверелә.

Габденнасыйр хәзрәт турында Ризаэддин Фәхреддин болай дип яза: “Габденнасыйр әл-Буави зирәк һәм тәкъва кеше иде. Фәкыйрьлек белән укып, үзенең тырышлыгы белән мөһим булган гыйлемнәрне алды. Шиһабетдин әл-Мәрҗани берлә икесе тәрикать зикере кылсалар да, гомерләрен гыйлем таратуга һәм укытуга сарыф иттеләр, мөрид тәрбия кылып шөгыльләнмәделәр”. (“Асар”, 4 т., 137 б.).

Шиһабетдин Мәрҗани аның турында болай ди: “Халык белән аралашуы аз иде, дан һәм кадер-хөрмәт күрү белән гомер кичерде. Әйләнә-тирәдә булган галимнәрнең мәшһүрләреннән иде”. (“Мөстәфадел-әхбар фи әхвале Казан вә Болгар”, 2 т., 283 б.).

Габденнасыйр хәзрәтнең гаиләсе дә шактый ишле була. Ул тормыш иптәше белән җиде кыз һәм ике ул үстерә. Зөһрә исемле кызы Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләрендә кияүдә була, Илһаҗир исемле икенче кызы Нургали Хәсән әл-Буавига кияүгә чыга.

Габденнасыйр хәзрәт 1886 елның 29 мартында 80 яшендә вафат була. Аның җеназасын Фәхреддин Мостаев укый. Танылган хәзрәт Буа шәһәрендәге татар зиратына җирләнә. Үзенең дәвамчысы булып калган улы, галим Гыйнатулла да озак яшәми, вафат була. Аның изге эшен бүтәннәр дәвам итә...

**Рәшид МАЛИКОВ,**
**Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты аспиранты**

27 НОЯБРЬ - ӘНИЛӘР КӨНЕ

# Әниләрне хөрмәт итик!

**Әниләргә хөрмәт ислам динендә генә түгел, барлык диннәрдә дә әни кешегә аерым урын билгеләнеп куелган.**

Ислам динендә исә, Аллаһы Тәгаләне хөрмәт иткәннән соң, әти-әниләребезгә итагать итәргә тиеш булабыз. Бу хакта пәйгамбәребезнең (Мөхәммәд сгв) күп кенә хәдисләре бар. Хәтта Аллаһы Сөбхәнәһу вә Тәгаләнең дә аятьләре китерелә. Мәсәлән, Коръәни-Кәримнең "Исра" сүрәсендә Аллаһ Раббыбыз болай ди: "Аллаһ хөкем итте вә әмер бирде, фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылыргa һәм ата-анага изгелек итәргә. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә олыгаю чорына керде икән, син аларга "уф" та дип әйтмә, аларны каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә, бәлки аларга һәрвакыт йомшак вә мөлаем сүзләр сөйлә!" (Ногмани тәфсире, 23 нче аять). Ягъни, әниләр һәрбер кеше өчен дә иң кадерле, иң якын кешеләр булып тора. Кешеләргә шундый сыйфат хас ки, ул әйберләрнең кадерен аны югалткач кына белә.

Мин үзем әнисез үстем. Әнием урынына мәрхүмә дәү әнием булды. Кайбер кешеләр әнисе исән-сау булуының кадерен белеп бетерми. Ә бит бу - Аллаһның зур рәхмәте һәм олы нигъмәте. Үги әниләрен дә бик хөрмәт итеп яшәүчеләр дә байтак!

Әйткәнемчә, әниләр хакында пәйгамбәребезнең (сгв) күп кенә хидисләре бар. Шуларның кайберләрен искә төшереп китсәк, бик тә әйбәт булыр иде. Пәйгамбәребез (сгв) әйткән: "Җәннәт әниләренең аяк астында". Икенче бер хәдистә (бу хәдис Тирмизи китабында китерелә): "Иң зур гаепле кеше - үз әти-әниләренә ярдәм күрсәтмәгән кеше. Һәм ул кеше җәннәткә керү юлын югалткан", дип әйтелә. Шулай ук матур мәгънәле тагын бер хәдис китерелә, шуны кыскача гына әйтеп китәсем килә. Бер кеше тәваф кылган вакытта, үзенең карт әнисен аркасына салып, аның белән тәваф кылган. Һәм дә пәйгамбәребезгә (сгв) килеп: "Йә, Аллаһның рәсүле! Әйтегезче, шушы әнием мине тугыз ай буена йөрәк астында мине йөрткәннең әҗерен әлеге хезмәтем белән түләдемме мин?" - дип сорый. Аңа җавап итеп пәйгамбәребез (сгв): "Юк. Син аның бер авырту мизгелен дә түләмәдең. Әниең кичергән авырлыкларның иң кечкенәсен дә син түли алмадың", - дип җавап биргән. Шушы хәдистә әниләребез безне тугыз ай буена йөрәк астында йөрткәннең әҗерен без аларга бер нәрсә белән дә түләп бетерә алмавыбыз турында әйтелә. Монда әле аларның безне тудырганы, ашатканы, киендергәне һ.б. әйтелми. Хәтта тәваф кылуның әҗере менә шушы әниеңнең бер авырту мизгелен дә алыштырмас, дип әйткән Мөхәммәд (сгв).

Яшьләргә әйтәсе килгән сүзем шул: без һәммәбез дә әти-әни булачак кешеләр. Бу дөньяда нәрсә генә эшләсәк тә, бөтенесе дә үзебезгә әйләнеп кайтачак. Әти-әниләребез белән нинди мөгамәләдә булсак, балаларыбыз да безнең белән дә нәкъ шундый ук мөнәсәбәттә булачак. Бу дөньяда бер генә әйбер дә болай гына булмый, һәрнәрсә дә кире әйләнеп кайта. Яхшылык - яхшылык белән, начарлык - начарлык белән кире әйләнеп кайта.

Л.С.Выготский дигән галим-психолог та: "Балалар бөтенесен күреп үсә", дигән нәтиҗәгә килгән. Динебездә шундый бер риваять тә бар. Бер кеше карт әтисен арбада алып барып, бер чокырга ташлаган икән. Өенә кайткач, арбасын да ташламакчы була, ди. "Әтием, тукта әле, син бу арбаны ташлама", - дип әйтә икән малае. "Нәрсәгә соң ул, улым?" - дигән сорауга улы: "Син картайгач, мин дә сине алып барып шул чокырга ташлармын", - дип җавaплаган. Ягъни, ни генә кылсак та, ул безнең үзебезгә әйләнеп кайтачак...

**Алан хәзрәт ПАНАРИН,**
**Казандагы "Ризван" мәчете имам-хатыйбы**

# НАСЫЙХ АГА НӘСИХӘТЕ

## Гап-гади кешегә күренекле булу өчен күп кирәкме?!

***Мамадыш Җәмигъ мәчетенең актив карты Насыйх Фазылрахманов кинәт кенә күренеклегә әверелде дә куйды. Аны һәркайда танылар. Бөтендөнья пәрәвез челтәре, газета-журналлар аның турында язмалар, аның фотолары белән тулган. Ә аксакал үзе бүгенге көндә хаҗ гамәле кыла. Барысына да "Бибинур" гаепле...***

**ШӘҺӘРЕБЕЗНЕҢ** Җиңү урамындагы бакчасы да, тәрәзә төпләре дә шау чәчәкләргә күмелеп утыручы бу мәһабәт йортка эшкә барганда көн дә игътибар итәм. Хуҗалары белән якыннан танышкач, аларга соклануым тагын да артты. Миннур апа белән Насыйх абый, уллары Илдар, киленнәре Наилә һәм өч оныклары белән тату гаилә корып, чын мөселманнарча матур гомер кичерә. Өлкән буын инде дистә еллар биш вакыт намазын калдырмый, мөәзин көн дә таң беленгәнче үк мәчеткә азан әйтергә ашыга. Йортлары зиратка якын гына урнашканга күрә, еш кына мәет күмү мәсьәләләре белән дә аңа мөрәҗәгать итәләр. Кеше гозерен беркайчан да кире какмый ул. "Бу ләхетләргә барыбызның да кереп ятасы бар бит әле, фани дөньяда кочтән килгәнчә берберебезгә ярдәмләшеп яшик", - ди Насыйх ага. 2005 елда аңа хаҗ гамәле кылып кайтырга насыйп була. Бу, әлбәттә, шактый чыгымлы эш, тик изге гамәлне үтәү - һәр мөселманга фарыз. Аксакал уйлап-уйлап утыра да, Саклык банкына барып, үзенә әлеге максатка ссуда сорый. Бирәләр. Аннары биш ел буе пенсиясен шунда гына түләсә түли, тик изге гамәлне үтәп кайту аңа рухи көч өсти. "Аллаһы Тәгаләнең берлегән, барлыгын тагын да тирәнрәк аңлап кайтасың. Могҗизалы, серле урыннар... Изге сәфәр үзенә гел тартып тора. Мин анда тагын барасымны тоеп яшәдем, янәдән шундый искиткеч мөмкинлек тудыруга булышканы өчен Мамадыш муниципаль районы башлыгы Анатолий Ивановка, туганнарыма мең рәхмәт", - ди хаҗи.

Казанның "Сабантуй" киностудиясендә төшерелеп, бөтен дөньяны шаулаткан, күп кенә күренекле фестивальләрдә лаеклы урыннар яулаган профессиональ татар киносына ул ничек барып эләгә соң?

"Наил хәзрәт көннәрдән бер көнне ураза вакытында мәчет картларын җыеп: "Әйдәгез әле, Алгайга барып кайтабыз", - дип, автобуска утыртып алып китте. Анда кино төшерәләр икән. Безне мал сайлаган кебек сайладылар. Минем сакал режиссёрның күңеленә хуш килде. Аны хаҗдан кайтканнан бирле кырганым юк, пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) сөннәте бит ул. Аннары: "Тешең алынамы?" - дип сорады. Протезны салып күрсәттем. Картайган көнендә үзеңне экраннан карап утыру хикмәт инде", - дип көлдергән иде ул тамашачыларны фильмны район мәдәният йортында тәкъдир итүдәге очрашуда. Әйе, Петербургтан килгән режиссёр Юрий Фетинг бабайларга чып-чын кастинг оештыра. "Насыйх Фазылрахманов - халык типажы, мәчеттә биш вакыт намазын укучы карт. Ул актёр түгел, тик ул кадрда гадәттәге үз тормышы белән яши. Мин аның иң яхшы башкарылган ир-ат роле өчен приз бирер идем, чөнки аныкы кебек йөз, йөрәк, караш актёрлар арасында юк. Бу рольгә халык артистларын да күпләп китерделәр, тик мин аны бер артистның да болай башкарып чыга алмасын аңладым", - ди ул матбугатка биргән интервьюсында.



Әхлакый кануннар, кешелеклелек хисләре югала барган бер чорда: "Үзегезне, төбәгегезне, мәдәниятегезне, телегезне саклагыз!" - дип чаң кагучы фильмда: "Фәкать Аллаһтан гына куркып, Аллаһ кушканча гына яшәргә тиешбез!" - дигән фикер буеннан-буена кызыл җеп булып сузыла. Авыл мәчетенең югалган нигез ташларын барәмтекләп җыючы, нәсел-шәҗәрәсен, милли гореф-гадәтләрне, йолаларны белүче, туган җир язмышын үз кулыбызга алырга өндәүче, бу дөньяда тамак турында гына түгел, рухи азык турында кайгырту кыйммәтләрәк икәнен яшәеше, кылган гамәлләре белән раслаучы авыл карты, аксакал Вәли образын бик оста, табигый башкара Насыйх ага. Хәер, тормышта да роле шул ук бит инде аның.

**Алсу ДИЯР.**
**Мамадыш шәһәре.**
**Автор фотосы.**
**Рәсемдә: Насыйх ага хатыны Миннур һәм оныгы Илназ белән.**

# СОРАУЛАРГА – ҖАВАП

***- Коръәнне хатын-кызлар да тутыра һәм багышлый аламы?***

- Әйе, хатын-кызлар Коръәнне тутыра да, багышлый да ала. Коръән тутыру - ул Коръәнне башыннан алып ахырына хәтле укып чыгу була.

Әмма бу мәсьәләнең тагын бер ягы бар. Бездә табыннарда Коръән укыла һәм багышлана. Менә бу очракта, әгәр табында хатын-кызга мәхрәм булмаган чит ирләр утыра икән, ул чагында хатын-кызның кычкырып Коръән укуы да, багышлавы да ярамый, дөрес булмый.

**ТР мөселманнары Диния нәзарәтендәге Казыйлар шурасының 43 нче утырыш КАРАРЫ. 14 ноябрь, 2011 ел**

* * *

***Җеназа намазы - фарыз кифая. Ник "Әлхәм" сүрәсе укылмый? Хәдисләрдә "Әлхәм" сүрәсе җеназа намазында укыла, дип әйтелгән.***

**РӘМИС. Апас районы**

Иң беренче чиратта, "намаз" дигән сүзгә тукталып үтәсе килә. Гарәп телендә намаз - "әс-салә" дип әйтелә. Шушы сүзгә аңлатма биргән галимнәрнең әйтүенә караганда, "әс-салә" - ул дога, диләр. Мәсәлән, Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребез Мөхәммәдкә (с.г.в.) салават әйтү хакында болай ди: "Чынлыкта, Аллаһы Тәгалә һәм аның фәрештәләре "йүсаллүнә"", ягъни, биредә дә "салә" дигән сүз куллана. Салават әйтәләр һәм дога кылалар пәйгамбәребезгә (с.г.в.), дип килә. Ягъни, пәйгамбәребезгә намаз укыйлар, дип тәрҗемә ителми, ә бәлки, рәсүлебезгә салават әйтәләр, дога кылалар, дип тәрҗемә ителә. Әлеге аятькә нигезләнеп, шуны әйтергә мөмкин: җеназа намазы дигәндә, "дога" дип тәрҗемә ителә. Ә догага "Әлхәм" сүрәсен кертү хәнәфи мәзһәбе буенча шарт түгел. Димәк, җеназа намазы - ул дога мәгънәсендә килә. Ул хакыйкый намаз булмаганлыктан (җеназа намазында рокугъ-сәҗдә булмагач), "Әлхәм сүрәсен уку да шарт түгел.

* * *

***"Мосафир" дигәнне ничек аңларга кирәк? Намаз укуда нинди җиңеллекләр бар?***

**РӘМИС. Апас районы**

Йөз чакрымга ниятләп, өеннән чыгып киткән кеше мосафир булып санала. Шулай ук берәр җиргә барып ирешкәннән соң, унбиш көннән артык яшәмәсә, ул шулай ук мосафир булып санала. Берәр барган шәһәрдә унбиш көннән артыграк яшәп калса, ул мосафирлыктан чыга. Мосафир кешенең дүрт рәкагатьле фарыз намазлары ике рәкагатькә кыскара. Шулай ук читек мәсьәләсендә дә бер уңайлык бар: мосафир кешенең өч тәүлеккә кадәр читек хөкеме саклана.

* * *

***Белгәнебезчә, Коръәннең 9 нчы "Тәүбә" сүрәсен укый башлаганда "бисмилла" әйтелми. Сүрәне укый башлагач, ниндидер сәбәпләр белән укуны туктатып, берникадәр вакыттан соң тукталган аятьтән укуны дәвам итә башлаганда, "бисмилла"ны әйтергә кирәкме (ярыймы) икән?***

***Мөхтәрәм хәзрәт Габделхак Саматов үзенең III томлык "Шәригать: вәгазь, хөкем, фәтва, җавап-савап, киңәшләр" исемле хезмәтендә (II китап, 214 нче бит) хәзрәти Галинең (р.г.) җавабын китерә. Ул, "бисмилла"да "иррахим" бар, ә кылычта рәхим юк, дип җавап бирде дигән. Бу җавап "Тәүбә" сүрәсенә тулаем кагыламы икән?***

**Казандагы "Тынычлык" мәчете мәхәлләсе мөселманнары исеменнән Рафаил ЧАНЫШЕВ.**

Бу хакта галимнәрнең берничә җавабы бар. Әлеге җавапларның һәрберсе урынлы дип әйтергә кирәк. Кайбер галимнәр, ""Тәүбә" сүрәсе ни өчен "бисмилла"сыз башлана?" дигән сорауга болайрак җавап бирә: ""Тәүбә" сүрәсе - ул "Әнфәл" сүрәсенең дәвамы булырга мөмкин. Шуңа күрә аның арасына "бисмилла" куелмаган". "Бисмилла" юк, димәк, ул "Әнфәл" сүрәсенең дәвамы булырга мөмкин, диләр. Икенче бер галимнәрнең әйтүенә караганда, "Тәүбә" сүрәсе "бисмилла"сыз башлана, чөнки "Тәүбә"дә күбрәк сугыш турында сөйләнелә. Ә сугыш - ул кан түгелү дигән сүз. Шушы вакыйганы аңлаткан вакытта Аллаһы Тәгаләнең "рәхимле", "шәфкатьле" дигән мөбәрәк исеме зекер ителми, дип аңлатма бирәләр. Әлеге ике фикер дә урынлы дип әйтсәк, ялгыш булмас.

Шунысын да искәртеп үтик: ниндидер сәбәпләр белән Коръән укудан туктап, калган җирдән укуны дәвам иттергәндә "Әгузе билләһи минәш-шәйтанир-раҗим" дип башлап китү хәерлерәк.

**Сорауларга Казан шәһәре казые Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИН җавап бирде**

# ӘНИ КАДЕРЕ...



*Дустымның туган көне җитә. Яшь-җилкенчәккә нәрсә инде аңа, күңел ачар өчен сәбәп кенә кирәк. Безне дә чакырды ул. Дөрес, билгеләнгән көнгә кадәр шактый вакыт бар әле, әмма башларда җил уйный, кан кызу, мәҗлесне ничегрәк үткәрү буенча идеяләр туып кына тора. Планнар күптөрле иде... Фатирда куну тулай торак "балалары" өчен үзе бәйрәм инде ул! Иптәш кызымны хөрмәт иткәнгә күрә, бармыйча калу һич ярамый... Менә санаулы көннәр үтеп тә бара... Бүләкләр дә алынган, киеп барырга "соңгы мода" күлмәкләр дә әзер... Беркөн, һич көтмәгәндә, шул иптәш кызым шалтыратты. Көр тавыш белән исәнләшүемә, ниндидер аклану тоташ кәефсезлек, читенсенү ишетелде аның тавышында:*

- Ни бит әле... Юк-юк, туган көн була, анысы... Ләкин бер мәсьәләне чишәсе бар - әнине берәр җиргә илтеп торырга иде. Син бит иң якын дустым, бәлки берәр нәрсә тәкъдим итәрсең?

Мин аптырашта калдым. Тел төбен дә аңлап бетерергә өлгермәдем, тагын сөйләп китте:

- Гарип минем әнкәй, "гарипләр арбасы"нда йөри... Дус кызларым һәммәсе дә тулы гаиләләрдән, әниемне аларга күрсәтергә оялам...

Шулчак Әмирхан Еникинең "Матурлык" хикәясе искә төште... Андагы төп герой Бәдретдин нинди шадра битле Әнисен иптәшләре янына алып чыгып таныштыра, ә монда... Иптәш кызына булган хөрмәтемнең әсәре дә калмады. Үз Әнисеннән, аны тудырган заттан ничек инде тартынырга була - башыма сыймый... Дуслар белән киңәшеп, туган көнне ачык һавада гына үткәрергә карар кылдык... Әмма минем өчен бәйрәмнең яме шуның кадәр генә иде... Миңа калса, әниләребез - безнең өчен Аллаһтан кала иң хөрмәткә лаек зат булырга тиеш. Аларның догасы кабул була. Картлык көннәрендә кадерлеләребезгә карата бары ихтирам, чиксез рәхмәт күрсәтелергә тиештер. Һәммәбез дә моны истә тотса иде!

**Зилә ФӘСХИЕВА, КФУның татар филологиясе бүлеге - Филология һәм сәнгать институты студенткасы**

# Балаларга – "Фатиха"

***Шушы көннәрдә генә татар-мөселман балалары өчен "Фатиха" китап-календаре дөнья күрде. Каюм Насыйри нигез салган календарьлардан алып бүген чыгып килгәннәренә кадәр - барысы да өлкән укучылар өчен булса, монысы - балаларга һәм үсмерләргә атап чыгарылган беренче календарь.***




"Максатыбыз олы - балалар күңелендә ислам динен өйрәнүгә омтылыш һәм теләк тудыру. Динебезне өйрәнеп, белеп һәм олылап үскән баладан исә югары әхлаклы, начар гамәлләрдән тыелып, игелекле эшләр кылырга тырышкан иманлы кеше үсәр", - диелә "Фатиха"ның кереш сүзендә. Китап-календарьда бала күңеленә якын булырдай кызыклы-гыйбрәтле хикәятләр, мавыктыргыч әкиятләр, уеннар, табышмаклар урын алган. Балалар һәм үсмерләр календарьдардагы "Аллаһның барлыгы", "Илаһи кодрәт", "Белеп торыйк", "Сорау-җавап", "Аллаһның исемнәре" һ.б рубрикаларда динебез нигезләренә кагылышлы белемнәрен тирәнәйтә алачак. Календарь җиде яшьтән алып унҗиде яшькә кадәр булганнарга тәкъдим ителә. Анда "Әти-әниләр өчен" дип аталган рубрика да бар. "Фатиха"ның эчтәлеге дә бай, бизәлеше дә матур. Календарьның төзүче-авторы - Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, журналист Нәсимә Садыйкова.

**MATBUGAT.RU**

# ӘЛМӘТТӘ НИЛӘР БАР?

***- 21 ноябрь көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең ревизия комиссиясе Әлмәт мөхтәсибәте һәм Әлмәт мәдрәсәсе эшчәнлеген тикшереп китте, - дип хәбәр итте Әлмәт шәһәре һәм Әлмәт районы имам-мөхтәсибе Рафикъ хәзрәт Миңнәхмәтов.***

"Мөхтәсибәттә хуҗалык һәм финанс эшләренә кагылышлы зур кимчелекләр табылмады, мөхтәсибәт эшчәнлеген тәртипкә салу уңайлы гына башкарыла. Тик мәдрәсә эшчәнлегендә кимчелекләр бар", - дип белдерде ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең ревизия комиссиясе рәисе Мирхәт Хәертдин улы Җамалиев. Мөфтиятнең ревизия комиссиясе эшендә кемнәр катнаша соң? Алар - Саба районы имам-мөхтәсибе Айнур хәзрәт Әхмәтов, Арча районы имам-мөхтәсибе Раил хәзрәт Гыйләҗев һәм Апас районы имам-мөхтәсибе Мирхәт хәзрәт Җамалиев.

29 ноябрь көнне Әлмәт Җәмигъ мәчетендә Татарстанның көнчыгыш төбәге казыяте утырышы узачак. Әлеге чарада Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәизнең дә катнашуы көтелә. Көн тәртибендә - имамнарның традицион ислам белән бәйле булган сорауларына җавап эзләү, экстремизмга каршы тору юллары турында сөйләшү.

Исегезгә төшерәбез: ТР көнчыгыш төбәге казыятенә биш район - Азнакай, Әлмәт, Зәй, Мөслим һәм Сарман районнары керә.

**Нияз САБИРҖАНОВ**

# ИГЪЛАН

**Мөселман яшьләре арасында Казан шәһәре спартакиадасы узачак.**

26 нчы ноябрьдән 2 нче декабрьгә кадәр Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм Казан шәһәре спорт комитеты тарафыннан III спартакиада уздырыла.

Ярышлар тәртибе түбәндәгечә:

*26 ноябрь - өстәл теннисы (егетләр һәм кызлар);*

*28 ноябрь - стритбол (егетләр һәм кызлар);*

*30 ноябрь - волейбол (егетләр);*

*2 декабрь - җиңел атлетика (800 метрга йөгерү, озынлыкка сикерү - егетләр).*

Ярышлар Казанның төрле спорт корылмаларында узачак.

Җиңүчеләр медальләр һәм дипломнар белән бүләкләнәчәк. Барлык төр ярышларда да җиңүче команда күчмә кубокка ия булачак.

Ярышларда 15 яшьтән 23 яшькә кадәргеләр катнаша ала.

**Мөрәҗәгать итү өчен телефон: 89274267918.**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 26.11.2011 | 7:09 | 8:39 | 13:02 | 15:15 | 16:21 | 17:51 |
| Якшәмбе | 27.11.2011 | 7:11 | 8:41 | 13:02 | 15:14 | 16:20 | 17:50 |
| Дүшәмбе | 28.11.2011 | 7:12 | 8:42 | 13:02 | 15:13 | 16:19 | 17:49 |
| Сишәмбе | 29.11.2011 | 7:14 | 8:44 | 13:02 | 15:13 | 16:18 | 17:48 |
| Чәршәмбе | 30.11.2011 | 7:16 | 8:46 | 13:02 | 15:12 | 16:17 | 17:47 |
| Пәнҗешәмбе | 01.12.2011 | 7:18 | 8:48 | 13:02 | 15:11 | 16:16 | 17:46 |
| Җомга | 02.12.2011 | 7:19 | 8:49 | 13:02 | 15:11 | 16:15 | 17:45 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №15 (112) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-515.

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 24 ноябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**